| “Каралды” | “ Килешенде” | “Расланды” |
| --- | --- | --- |
| Методик берләшмә җитәкчесе<br>__________ Гиззатуллин Ш. С.<br>Беркетмә №<br>август, 2023 | Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениясе «Татарстан Республикасы Буа шәһәре М. М. Вахитов исемендәге гимназия”нең Тәрбия эшләре буеча директор урынбасары:<br>Закирова А. С. | Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениясе «Татарстан Республикасы Буа шәһәре М. М. Вахитов исемендәге гимназия”нең директоры<br>Л. Б. Зиннатуллин<br>Боерык № сентябрь 2023 ел |

# Озайтылган көн төркеменең әңгәмәләр планы

## Озайтылган көн төркеменең үткән уку елы эшенә анализы

Озайтылган көн төркеме эти – әниләрнең гаризаларына нигезләнеп гимназия директоры приказы белән оештырылды.

**Озайтылган көн төркеменең төп максаты:**

-Укучыларның сәламәтлеген ныгыту;
-Укучыларның белемен ныгыту, баету;
-Укучыларда , мөстәкыйльлек тәрбияләү;
-Укучыларда дуслык, иптәшлек хисе тәрбияләү;
-Укучыларның кызыксынучанлыгын, фикерләү сәләтен үстерү
Үземнең эшемдә түбәндәге юнәлешләрне билгеләдем:

- Иҗади күзаллау;
- Хезмәт тәрбиясе;
- Спорт һәм сәламәтләндерү;
- Коммуникатив – бергәләп эшләү.

Иҗади кузаллау тәрбиясен тормышка ашыру өчен түбәндәге эшләр үткәрелде:"Яфрак "рәсеме ясау, "Көз темасына" рәсемнәр ясау.

Хезмәт тәрбиясе тәрбияләүдә уңай нәтиҗәләргә ирешү өчен түбәндәге әңгәмәләр үткәрелде:"Бүлмә гөлләре", "Хезмәт нәрсә ул?" Табигатьне аңларга, яратырга өйрәтү укучыларга экологик тәрбия бирүдә иң мөһим бурычларның берсе .Экологик бәйләнешләрне өйрәнү балаларның логик фикерләү сәләтен, хәтерен, күзаллауларын, табигатькә сакчыл караш һәм шулай ук сөйләмнәрен үстерүгә дә ярдәм итә.Моны гамәлгә ашыру өчен табигатьтәге бар нәрсә дә үзара бәйле икәнлеген дәлилләү , табигатьтә үз-үзләрен дөрес тоту күнекмәләрен үстерү.

Табигать турындагы белемнәр халык авыз иҗатында киң чагылыш тапкан.Әкият, мәкаль,әйтем, сынамыш һәм табышмакларда күп кенә

экологик мәгълүмат бирелгән. Бу чыганакның төп өстенлеге шунда: белемнәр балаларга мавыктыргыч рәвештә җиткерелә.

Озайтылган көн төркемендә экологик тәрбия максатыннан халык авыз иҗатының бар төре булган табышмакларны еш кулланам. Аларның күбесе еш очрый торган табигать күренешләренә багышланган(“Ак яулыгым төшеп калды”...), яки табигый җисемнәргә хас үзенчәлекләр турында( “Җәен соры, кышын ак, аңа шулай яхшырак”).Табышмаклар балаларда зирәклек, күзәтүчәнлек кебек сыйфатлар тәрбияли.Табышмакларны кулланып, кроссвордлар төзергә мөмкин.

Халык авыз иҗатының икенче бер төре - мәкаль.Мәкальләр арасында табигатькә багышланган һәм экологик тәрбияне күз алдында тотканнарын сайлап кулланып нәтиҗә ирешер була. Мәсәлән, ”Суга сусаган - чишмә эрчегән”, “Агач утырткан - ага булган”,”Кул пычранса, су белән юарсың,су пычранса ни белән юарсың?” һ.б. шундый мәкальләрдән файдаланабыз. Татар халык мәкальләре арасында чәчәкләргә багышланганнары искиткеч күп. Алар белән танышу кече яшьтәге мәктәп балаларын, беренчедән, үсемлекләр дөньясын танып-белергә өйрәтсә, икенчедән , бу матурлык белән хозурланырга, аның кадерен белергә өйрәтә. Агачлар турындагы мәкальләр балаларга әйләнә тирәне танып-белүдә дә ярдәм итә.

Сынамышларны да шулай ук киң кулланырга була.Әйтем һәм сынамышларны балаларның хәтеренә сеңдерү өчен, бу эшне экологик лото рәвешендә дә оештырабыз. Мәкаль, әйтем , сынамыш ике өлешкә бүленә. (Мәсәлән, беренчесе – “урман утырткан”, икенчесе – “ачлык күрмәс”), һәр өлеш аерым карточкага теркәлә,укытучы кушуы буенча, укучылар мәгънә ягыннан туры килүче өлешләрне эзлиләр.

Һәр ел саен гимназиядә бәйрәмнәр үткәрү гореф-гадәте бар. Көз көне “Сөмбелә”, язын “Нәүруз” бәйрәмнәре үткәрелә. Яз саен “Кошлар көне” уздырыла. Бу матур бәйрәмнәрдә балалар бик теләп катнашалар Алар табигать турында шигырьләр өйрәнәләр, рәсемнәр, аппликацияләр ясыйлар.

Мәсәлән «Көзге унышлар», «Яфраклар», уеннар уйныйлар («Утыр, утыр кәбестә»).

Экологик белем һәм тәрбия бирүдә әдәби әсәрләрнең, әкиятләрнең әһәмияте бик зур.Мәсәлән, «Шалкан әкияте», М.Җәлилнен «Кечкенә дусларга», Ф. Яруллинның «Яз кайда кышлый» .

Үсемлекләр, җәнлекләр яки табигатьне саклауга багышланган әңгәмәләр үткәрелә. («Урман безнең байлыгыбыз», «Гөмбәләр патшалыгында», « Бүлмә гөлләре», «Янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре».) Мәсәлән «Чишмәләр» турында әңгәмәдән өзек.( Һәрбер чишмәнен исеме була, аны каян чыкканына, кем карап торганына карап исемлиләр, бәлки сез дә яңа калкып чыккан чишмә табарсыз да, аны чистартып карап торырсыз, һәм ул чишмәне сезнен исемегез белән атап йөртерләр.

Балалар, ә сез беләсезме, чишмәләр каян килә?

- Җир астыннан.

-Әйе, бик дөрес. Чишмә суы җир астыннан, тау арасыннан я тау итәгеннән агып чыга, ә чишмә суы улактан ага. Улак элек агач каерысыннан булган, ә хәзер улакларны тимер торбалардан ясыйлар, аларны тузган саен алыштырып торалар. Чишмә изге урын, чөнки аннан агып чыккан су кешеләргә, табигатькә, кошларга, хайваннарга яшәү чыганагы булып тора. Шуңа кешеләр аны матурлый, бизи, чистартып тора. Тыңлагыз, әле сезгә кечкенә генә шигырь юллары укыйм.

Бер эсседән качып, бер суыктан
Кыргыйлыктан җаннар көйгәндер
Тау астыннан чишмә тибеп чыккан
Бер яхшылык булсын дигәндер.

Соңрак кешеләр суны кое казып коелардан ала башлаганнар, ә хәзер исә су өйләрдә торбалар аша краннардан ага. Шагыйрьләр чишмәләрне мактап шигырьләр язган, ә композиторлар шул шигырьләрне көйгә салган. Әйдәгез,

хәзер балалаларны тыңлыйк. (Балалар шигырьләр сөйлиләр, җырлар җырлыйлар.)).

Математикадан да экологик темаларга күп төрле мәсьәлә чишәргә була.

Экологик темага шигъри арифметик табышмаклар да бар.

Йомгаклап әйткәндә, экологик тәрбия бирерлек моментларны күп дәресләрдә төрлечә кулланырга,файдаланырга була.

Табигатьнең гүзәллеген тоя белгән, кирәклеген аңлаган, миһербанлы, кешелекле балалар тәрбияли алсак иде. Һәм үзебез дә аларга бар нәрсәдә дә үрнәк булсак иде.Чөнки:" Үрнәк - иң яхшы тәрбия",- дип әйткән әби-бабаларыбыз, ата-аналарыбыз.

Укучыларны бездә кышлаучы һәм күчмә кошларны танырга өйрәтү, аларның яшәү рәвешләре белән таныштыру, кошларга ярдәм кирәклегенә төшендерү; табигатьне саклау хисе булдыру нигезендә "Кошлар – безнең дусларыбыз" дигән чара уздырылды.

Спорт һәм сәламәтләндерү тәрбиясен тормышка ашыру өчен түбәндәге эшләр үткәрелде:" Дөрес туклану- сәламәтлекнең нигезе".,Саф һавада хэрэкэт уеннары».

# Атналык режим

| | |
|---|---|
| Дүшәмбе | әңгәмә үткәрү |
| Сишәмбе | оста куллар: аппликация ясау, |
| | пластилиннан әвәләү |
| Чәршәмбе | рәсем ясау, |
| Пәнҗешәмбе | китаплар уку |
| Җомга | уеннар өйрәнү, уйнау |

# Көндәлек режим

| | |
|---|---|
| 11.00-12.00 | Балаларны кабул итү |
| 12.15-13.00 | Ирекле уеннар |
| 13.00-14.20 | Саф һавада ирекле уеннар |
| 14.20-15.20 | Дәресләр әзерләү |
| 15.20-16.00 | Әңгәмә үткәрү |
| 16.00-16.30 | Өстәл уеннары уйнау, рәсемнәр ясау |
| 16.30-17.00 | Балаларны өйләренә озату |

## Тәрбия максаты һәм бурычлары

1. Укучыларның гомуми белем һәм күнекмәләрен формалаштыру; аларда мөстәкыйллек тәрбияләү.
2. Мәктәптә, өйдә, урамда, җәмәгать урыннарында үз-үзләрен әдәпле тотуларына ирешү.
3. Туган илебезгә, туган телебезгә мәхәббәт, табигатькә аңлы караш тәрбияләү. Гайләне, иптәшләрне хөрмәтләү хисе тәрбияләү.
4. Ата-аналар ярдәмендә балаларның сәламәтлеген саклау буенча тиешле чаралар уздыру, кечкенәдән үк көндәлек режимны дөрес оештыруга һәм файдалы итеп үткәрергә өйрәтү.
5. Укучыларның дәрестән соң эшләрендә юнәлеш бирү һәм өй эшләрен әзерләүдә булышу.

## Укучылар белән индивидуаль эшләү.

1.Класс җитәкчеләре белән сөйләшеп, авыр үзләштерүче укучыларны билгеләү.

сентябрь

2.Индивидуаль эшләүче балаларга дәфтәрләр башлату.

сентябрь

3.Укучыларның ата-аналары белән сөйләшү.

даими

4.Дәрестә булып, укулары белән кызыксыну.

даими

5.Класс җитәкчеләре белән элемтәдә тору, консультацияләр алу.

даими

6.Бу укучыларга өстәмә эшләр бирү.

даими

## Спорт-сәламәтләндерү юнәлеше

**Максат:** яшьләрдә формалашу өчен иң уңайлы шартлар тудыру; мәктәп укучыларының сәламәт яшәү рәвешенә төп юлларның берсе буларак - уңышка ирешү; күчмә уеннар белән шөгыльләнүгә тарту, аларны куллану моторның ачык төрләренә кызыксыну формалаштыру.

**Бурыч:**

башлангыч сыйныф укучыларының дәрестән тыш хәрәкәт активлыгын тәэмин итү;

балаларны хәрәкәтчән уеннар һәм мөмкинлек белән таныштыру; аларны ялны оештырганда куллану;

илебезнең иң борынгы һәм иң борынгы казанышларының берсе үсемлекләр утырту, территорияне чистарту һ. б.); - әйләнә-тирә дөнья турында дөрес фикерләр формалаштыру; табигатьтә осталык- үзеңне дөрес тоту, табигатьне өйрәнү һәм саклау теләге;

акыллылык, сөйләм, фантазия, аралашу осталыгын тәрбияләү.

## Гомуммәдәни юнәлеш

**Максат:** тәрбияләнүчеләрнең эстетик, рухи-әхлакый үсешен тәэмин итү., кызыксынуны һәм җаваплылыкны үстерү; театр һәм актерлык эшчәнлеге сәнгате.

**Бурыч**

балаларны төрле театр һәм музейлар белән таныштыру;

балаларның төрле иҗат төрләрен этаплап үзләштерү;

балаларның сәнгать күнекмәләрен камилләштерү ;

бирелгән шартларда социаль тәртип күнекмәләрен модельләштерү;

сөйләм культурасын үстерү;

эстетик тәрбияне үстерү;

үзендә һәм башкаларда бик кадерле сыйфатлар: игелек, эш сөючәнлек, башкаларның иҗатына хөрмәт кебек сыйфатлар тәрбияләү.

## Гомуми интеллектуаль юнәлеш

**Максат:** укучыларның танып белү сәләтен үстерү; һөнәрләр дөньясы турында төрле тәэсирләр булдыру.

**Бурыч:** укучыларны һөнәрләр дөньясының төрлелеге, үзенчәлекләре белән таныштыру.

## Рухи-әхлакый юнәлеш

**Максат:** яшьләрдә аралашу күнекмәләрен формалаштыру; укучыларның әхлакый сыйфатларын үстерү һәм камилләштерү, юнәлеш гомумкешелек кыйммәтләренә.

**Бурыч:** коммуникатив аралашу һәм хезмәттәшлек күнекмәләрен укыту; кече яшьтәге укучыларда сөйләм этикеты һәм мәдәнияте күнекмәләрен формалаштыру ; аралашу процессында аралашу сәләтен үстерү; кеше мөнәсәбәтләре, әхлакый кыйммәтләр дөньясына керешү, шәхес формалаштыру.

## Социаль юнәлеш

**Максат:** баланы актив әгъза итеп тәрҗемә итү өчен шартлар тудыру үзбилгеләнергә сәләтле гражданнар җәмгыяте , үзгәртү проектларын эшләү, әлеге проектларны тормышка ашыру.

**Бурыч:** - төп кыйммәтләргә уңай караш формалаштыру; хезмәт күнекмәләрен формалаштыру, хезмәткә уңай караш , җаваплылык һәм үз-үзеңә ышаныч хисе тәрбияләү;

В этом документе пронумеровано,

прошнуровано и скреплено печатью

(четырнадцать ) листов

Директор гимназии Л. Б. Зиннатуллин